әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

7 пунктта:

сигезенче абзацка «, вәкаләтле затның имзасы һәм кредит оешмасының мөһере белән таныкланган» сүзләрен өстәргә;

унҗиденче абзацка «, вәкаләтле затның имзасы һәм кредит оешмасының мөһере белән таныкланган» сүзләрен өстәргә;

унтугызынчы абзацка «, транспорт чарасын теркәү турында таныклык, машинаны теркәү турында таныклык» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга Сөт кәҗәләрен үрчетүне һәм (яисә) тотуны гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә азык сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен, Сугару һәм киптерү системаларын, шулай ук аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен өстәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 397 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 июнь, 734 нче карары редакциясендә)

Сөт кәҗәләрен үрчетүне һәм (яисә) тотуны гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә азык сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип сөт кәҗәләрен үрчетүне һәм (яисә) тотуны гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан тыш) агымдагы елның терлек азыгы сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш) субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, сайлап алуда катнашучылар).

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган «терлек азыгы» төшенчәсе сөт кәҗәләрен ашатканда кулланыла торган азык һәм азык өстәмәләренең барлык төрләрен үз эченә ала.

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башланган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 14 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итепә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән тыелып калган (калганнар) дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын.

5. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары:

сайлап алуда катнашучы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

хисап һәм агымдагы елларда сөт кәҗәләрен үрчетү һәм үстерү, кәҗә сөтен җитештерү һәм сату эшчәнлеген сайлап алуда катнашучы тарафыннан гамәлгә ашыру;

агымдагы елның 1 гыйнварына милек шартларында һәм (яисә) сөт кәҗәләренең баш санын арендалау шартларында булу;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел,

30 июнь, 514 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан финанслаша торган сарыкларның һәм кәҗәләрнең товар ана сарыкларын тотуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан гамәлгә ашырылган һәм (яисә) үзендә эшкәртелүгә һәм (яисә) эшкәртелүгә тотылган, федераль бюджеттан финанслаша торган эшкәртү оешмаларына суюга сарыклар һәм кәҗәләр җитештерүгә чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе нигезендә агымдагы елда субсидияләр алу факты булмау.

6. Сайлап алуда катнашучы заявка бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән дә артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка, башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау ;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү

коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.

7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча тутырылган заявка;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан гариза бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмәләр ( сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган, заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

Россия Федерациясенең статистика буенча Дәүләт комитеты раслаган форма буенча 2016 елның декабрендәге хайваннарның хәрәкәт итүе турында эчке файдаланудагы хисап;

сөт кәҗәләренең баш санын арендалау шартнамәсенең күчермәсен (булган очракта);

агымдагы елның 1 гыйнварына сөт кәҗәләренең баш саны турында мәгълүмат, аның нигезендә статистик хисап формалаштырылган;

агымдагы елның 1 гыйнварына бухгалтерлык хисабы нигезендә, сайлап алуда катнашучы җитәкче һәм баш хисапчысы тарафыннан таныкланган сөт кәҗәләренең ана баш саны турында белешмәләр;

статистика буенча, сайлап алуда катнашучы җитәкче һәм баш бухгалтер тарафыннан таныкланган Россия Федерациясе Дәүләт комитеты тарафыннан расланган форма буенча агымдагы елның 10 аенда кәҗәләрнең уртача баш саны турында белешмәләр;

терлек азыгы сатып алуга шартнамәләрнең күчермәләре;

агымдагы елда терлек азыгы сатып алуга йөкнамәләр күчермәләре;

агымдагы елда терлек азыгы сатып алуга түләү йөкләмәләре күчермәләре;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы, заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

8. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларны кабул итү срогы эчендә заявкаларны, керү тәртибе буенча аларның датасын һәм вакытын күрсәтеп, «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән гаризалар кабул итү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә сайлап алуда катнашучыларны тикшерә һәм тапшырылган документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү йә заявканы кабул итүдән баш тарту турында) реестр төзи һәм раслый;

сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

9. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучыларның бу Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявканың сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

10. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән алып биш эш көне эчендә субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидия алучы тарафыннан Министрлык билгеләгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе;

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучылар белән Татарст ан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

11. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән килешүләргә кул кую срогы чыккан көннән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

12. Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше агымдагы елда терлек азыгы сатып алуга бәйле чыгымнардан гыйбарәт.

13. Әлеге Тәртипнең 1 пункты (W) (сумнарда) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = K \times C,$$

монда:

K - агымдагы елның 10 аенда кәҗәләрнең уртача баш саны, баш саны;

C - бер баш кәҗәгә исәпләгәндә 3 300 сумга тигез субсидия ставкасы.

Шул ук вакытта субсидия күләме агымдагы елда терлек азыгы сатып алуга тотылган факттагы чыгымнарның 50 процентыннан арта алмый (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш).

Агымдагы елның 10 аенда кәҗәләрнең уртача баш санын исәпләү Федераль дәүләт статистика хезмәтенең «Авыл хуҗалыгына һәм әйләнә-тирә мохиткә федераль статистик күзәтүне оештыру өчен федераль статистик күзәтү рәвешләрен раслау турында» 2019 елның 18 июлендәге 412 нче номерлы боерыгында каралган «Терлекчелекнең торышы турында белешмәләр» 24-СХ номерлы федераль статистик күзәтү формасын тутыру күрсәткечләре белән аналогия буенча гамәлгә ашырыла.

14. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

агымдагы елның 1 гыйнварына карата субсидия бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына сөт кәҗәләренең ана баш санын саклап калу;

агымдагы елда, субсидия бирү елыннан килүче елның 1 гыйнварына торышы буенча, хисап елына кимендә 1 процентка сөт җитештерүне арттыру.

Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында, субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.

15. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

әгәр субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән булса, субсидия алучы субсидия акчасын түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә ($V_{\text{кире кайтару}}$) кире кайтара:

$$V_{\text{кире кайтару}} = (V_{\text{субсидия}} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{\text{субсидияләр}}$ – агымдагы елда субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме, сум;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләренең фактта ирешелгән күрсәткечләре;

S – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең план буенча күрсәткечләре.

Субсидия акчасын кире кайтару күләме исәпләп чыгарылганда коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәү дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай мәгънәләре кулланыла.

Министрлык килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә почта аша, тапшыру турында хәбәр итү кәгазен теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, субсидия акчасын кире кайтару хакында хәбәрнамә җибәрә.

16. Әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән акчаның Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә Министрлык тарафыннан мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

17. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

18. Субсидия алучылар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле вазыйфаи затларга йөкләнә.

19. Бюджет акчасын файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

_______________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 397 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 июнь, 734 нче карары редакциясендә)

Сугару һәм киптерү системаларын, шулай ук аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), кимендә бер календарь ел эшчәнлеген гамәлгә ашыручы агросәнәгать комплексы оешмаларына сугару һәм киптерү системаларын, шулай ук аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидия, сайлап алуда катнашучылар, мелиорация проекты, мелиорация объекты).

Өстәлгән бәягә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүченең вазыйфаларын үтәүдән азат итү хокукын файдаланучы субсидия алучылар өчен чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә, өстәлгән бәягә салым суммасын да кертеп, әлеге пунктта күрсәтелгән максатларга чыгымнар суммасыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

2. Субсидия бирү турында шарт булып сугару техникасын мелиорация объекты файдалануга тапшырылганнан соң ике ел дәвамында сатып алу турында һәм сугару техникасы сатып алганнан соң өч ел дәвамында авыл хуҗалыгы культураларын сугару өчен мелиорация объектыннан файдалану турында йөкләмә була.

3. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча,

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

5. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башланган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 16 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән тыелып калган (калганнар) дип тану шартларын;

Бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң була алмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

6. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

үз акчалары исәбеннән мелиорация проектының смета бәясенең 5 процентын түләү (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш);

мелиорация объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе белән проект-смета документлары булу (төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт башкарганда Россия Федерациясе законнары нигезендә смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә дәүләт экспертизасы уздыру таләп ителгән очракларда).

7. Сайлап алуда катнашучы заявка бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән дә артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.

8. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы бирә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турындагы башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) сайлап алуда катнашучының ризалыгы, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы (физик затлар өчен) бирелгән, үзенең түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада булган заявка;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан гариза бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмәләр ( сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе (сайлап алучы тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

мелиорация объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау буенча проект-смета документациясе күчермәсе;

мелиорация объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсенең күчермәсен (төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт башкарганда Россия Федерациясе законнары нигезендә смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә дәүләт экспертизасы уздыру таләп ителгән очракларда);

мелиорация объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкару планлаштырыла торган җир кишәрлекләренә хокук билгели торган документларның күчермәләрен;

агымдагы яисә хисап финанс елында төзелгән мелиорация объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга подряд шартнамәләренең күчермәләрен;

агымдагы яисә хисап финанс елында төзелгән мелиорация объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм капиталь ремонтлаганда төзелеш контроле уздыруга шартнамәнең күчермәсен;

сугару техникасын мелиорация объекты файдалануга тапшырылганнан соң ике ел дәвамында сатып алу турында һәм сугару техникасы сатып алганнан соң өч ел дәвамында авыл хуҗалыгы культураларын сугару өчен мелиорация объектыннан файдалану турында гарантияле хат;

мелиорация проектының смета бәясенең 5 процентын сайлап алуда катнашучы тарафыннан үз акчалары исәбеннән түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре күчермәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы, заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

9. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларны кабул итү срогы эчендә заявкаларны, керү тәртибе буенча аларның датасын һәм вакытын күрсәтеп, «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында реестр төзи һәм сайлап алуда җиңүче турында йә заявканы алудан баш тарту турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

10. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявканың сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең  6 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

11. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 10 эш көне эчендә субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидиянең максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше, субсидия күләме һәм аны күчерү сроклары;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидия алучы тарафыннан Министрлык билгеләгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела;

субсидия алучының, субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм $^{2692}$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия $^{\text{бирү}}$ тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучылар белән Татарст ан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

12. Бу Тәртипнең 11 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә имза куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

13. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән килешүләр төзүне төгәлләү срогы көненнән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

14. Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре: мелиорация объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау буенча проект-смета документларында каралган эшләр өчен түләү (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып).

15. Әлеге Тәртипнең 1 пункты (W) (сумнарда) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = P \times 95\%,$$

монда:

P - әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән эшләрнең смета бәясе (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш), сум.

16. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

субсидия бирү елыннан алдагы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга субсидия бирелгән мелиорация объектын файдалануга кертү, берәмлекләрдә;

мелиорация объектын кулланышка керткәннән соң биш ел эчендә авыл хуҗалыгы культураларын сугару өчен мелиорация объектын куллану, гектарларда.

17. Субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 25 көненнән дә соңга калмыйча, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында;

субсидия бирү елыннан соңгы елдан башлап, җиде ел дәвамында, 1 февральгә кадәр, субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләренә ирешү турында, түбәндәге документлар кушымтасы белән:

«Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» КС-2 номерлы статистик форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында актларның күчермәләрен;

башкарылган эшләр бәясе турында белешмәләр һәм «Башкарылган эшләр һәм чыгымнар бәясе турында белешмә» КС-3 номерлы статистик форма буенча чыгымнар күчермәләре;

башкарылган чыгымнарны раслый торган түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

мелиорация объектында эшләрнең билгеле бер төрен үтәү процессын һәм ахыргы нәтиҗәне чагылдыра торган 10 × 15 см дан 21 × 29,7 см га кадәр (А4 форматы) зурлактагы панорамалы төсле фотофиксацияләр, арткы ягында

субсидия алучыны, районны, башкарылган эш төрен һәм аны үткәрү датасын күрсәтеп, датаны күрсәтеп, җитәкче имзасы һәм субсидия алучының мөһере белән танылканган;

«Төзелеше тәмамланган объектны кабул итү комиссиясе тарафыннан кабул итү акты» КС-14 номерлы статистик форма буенча мелиорация объектын кабул итү актлары күчермәләре;

авыл хуҗалыгы культураларын сугару процессын чагылдыра торган 10 × 15 см дан 21 × 29,7 см га кадәр (А4 форматы) зурлыктагы панорамалы төсле фотофиксацияләр.

18. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, субсидия алучы субсидия акчасын түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә ($V_{\text{кире кайтару}}$) кире кайтара:

$$V_{\text{кире кайтару}} = (V_{\text{субсидия}} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{\text{субсидия}}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече.

Субсидия акчасын кире кайтару күләме исәпләп чыгарылганда коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай мәгънәләре кулланыла.

Министрлык килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә почта аша, тапшыру турында хәбәр итү кәгазен теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, субсидия акчасын кире кайтару хакында хәбәрнамә җибәрә.

19. Әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән акчаның Татарстан Республикасы бюджеты керемenә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә Министрлык тарафыннан мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

20. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

21. Субсидия алучылар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле вазыйфаи затларга йөкләнә.

22. Бюджет акчасын файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.